| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕМАШЛЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>422658, с. Большой Машляк, ул. Центральная, дом 20 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗУР МӘШЛӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>422658, Зур Мәшләк, Центральная урамы, 20 нче йорт, |
|---|---|
| Тел.: (84361) 33613, факс: (84361) 33613 , e-mail:BmSl.Rs@tatar.ru | |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 елның 14 октябре** **Зур Мәшләк авылы** **№ 32**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы “Үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында” 5 номерлы карары белән расланган васыятьнамәләр һәм ышанычнамәләрне таныклау буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү Административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 26 июлендәге “Россия Федерациясе нотариат турында законнар Нигезенә һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 16.1 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында” 226-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Зур Мәшләк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы “Үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында” 5 номерлы карары белән расланган васыятьнамәләр һәм ышанычнамәләрне таныклау буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) Карарның 1.5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

“1.5.Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәләрне таныклау буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламенты (Кушымта №5).”;

1.2)5 номерлыкушымтада:

а) исемнеяңаредакциядәбәянитәргә:

“Күчемсезмөлкәтбеләнфайдаланугаышанычнамәләрдәнгайреышанычнамәләрнета ныклаубуенчаүзидарәлекхезмәтекүрсәтүадминистратив регламенты”;

б) 1.1, 3.3.1. пунктларында “васыятьнамәләрне таныклау буенча һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 1.4 пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга;

г) 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.1. Үзидарәлекхезмәтененңисеме | Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәне таныклау | “Россия Федерациясенең нотариат турындаз аконнар Нигезе” (РФ ЮС тарафыннан расланган 11.02.1993 №4462-1) |

д) 2.3 һәм 2.4 пунктларынтүбәндәгередакциядәбәянитәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.3.Үзидарәлек хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсенн тасвирлау | Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәне таныклау буенча нотариаль гамәлләр кылу. Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәне таныклау буенча нотариаль гамәлләр кылуны кире кагу. | |
| 2.4.Үзидарәлек хезмәте күрсәтү срогы | Күчемсезмөлкәтбеләнфайдаланугаышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәләрне таныклау мөрәҗәгать иткән мизгелдән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла | |

е) 3.4.1. пунктыныңтугызынчыабзацында “васыятьнамәләрненотариальтаныклауһәм” сүзләрентөшереп калдырырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Зур Мәшләк авылы, Школьная урамы, 13А йорт; Югары Мәшләк авылы, Нариманова урамы, 24А йорт , Бикчурай авылы М.Горький урамы, 50 а йорт һәм
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге башлыгы М.Г.Заһидуллин